12+
# DARELFONUN
УНИВЕРСИТЕТ
Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы **20** гыйнвар, **2017** ел № 1 (154)



Ләйлә Сабирова фотосы

# Студентлар урамында бәйрәм!

Гыйнвар... Бу айда борчу да, күңелле вакыйгалар да мулдан. Сессия, студентлар көне... Сессия дигәннән, инде ул күбегезнең тәмамлангандыр да. Димәк, студентлар көнендә рәхәтләнеп бәйрәм итсәң дә була. Зачеткада 4-5ле, баштa акыллы фикер һәм белем, ә кесәдә бер айдан буласы стипендиягә өмет!

## ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Бу атнада КФУ ректоры **Илшат Гафуров** Студентлар шәһәрчегендә (Г.Кутуй урамы, 2) урнашкан төзекләндерелгән ашханә ачылышында катнашты. Биредә һәр көнне җылы һәм тәмле ризык белән 1500 кеше туклана алачак, ә янәшәдә урнашкан 6 тулай торакта 4000гә якын студент яши. 2 ел эчендә бинага, аның инфраструктурасына 50 млн акча сарыф ителгән, тагын 21 млн җиһазлар алуга тотылган.

## АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ

21 нче гыйнварда Л.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында **ачык ишекләр көне** узачак. Чыгарылыш сыйныф укучыларына компетентлы кешеләрдән уку-укыту мәсьәләләренә, керү имтиханнарына кагылышлы сорауларга җавап алу, институт, укытучылар һәм студентлар белән танышу өчен иң яхшы мөмкинлек. Ә 22 нче гыйнварда сезне Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбендә көтәләр.

## 4 ЕЛДАН СОҢ...

«Вести в субботу» тапшыруын алып баручы **Сергей Брилев** кабаттан КФУга килде. Аның алдагы килүендә Казан университеты яңарак кына федераль статуста эшли башлаган иде. Бүгенге очрашуда каләм әһелләрен әзерләү турында гына түгел, вузларда яңача эш системасы турында да фикер алышынды. Очрашу кунакның Студентлар мәгълүмати агентлыгына һәм КФУ телевидениесенә биргән зур интервьюсы белән тәмамланды.

## БИЛГЕСЕЗ ЛОБАЧЕВСКИЙ

КФУда Н.ЛОБАЧЕВСКИЙ ЕЛЫ БАШЛАНЫП КИТТЕ. БЕЗ ЗУР ФӘННИ АЧЫШЛАРЫ БЕЛӘН ДӨНЬЯГА ТАНЫЛГАН ГАЛИМНЕ НИ ДӘРӘҖӘДӘ БЕЛӘБЕЗ СОҢ?



1802 елда Прасковья Лобачевская улларын: олысы Александр, уртанчысы Николай һәм төпчеге Алексейны Казанга алып килә. Алар, сынауларны уңышлы үтеп, гимназиягә кабул ителәләр. Бертуган Лобачевскийлар өчен гимназия, ә аннан соң университет икенче йортларына әверелә.

Гимназиядә тору, уку шартлары кырыс була. Биналар яхшылап җылытылмый, юыну бүлмәсендә чират, ызгыш-талаш. Физик кыенлыклардан тыш, шәхескә карата зур басым ясала. Беркем дә акча һәм шәхси әйберләрен үзендә саклый алмый. Якыннар белән хат язышу да бары тик надзирательләр аша башкарыла. Николай Лобачевский шундый мохиттә үсә.

Николайның гимназиядәге тормышы турында бик аз билгеле. Аның акыллы һәм тырыш студент булуы, бигрәк тә күңеленең математика һәм латин теле фәннәренә ятып торуы турында гына истәлекләр сакланган.

1804 елда Казан император университеты ачыла. Бертуган Лобачевскийларның әниләре аларны шунда калдырырга була. Университетта кадрлар кытлыгы нык сизелә. Наполеон сугышлары белән чирләгән Көнбатыш Европа галимнәре Казанга чакыруны бик теләп кабул итәләр. Шундыйлардан алга таба Н.Лобачевскийның фәнни эшчәнлегенә һәм шәхесенә зур йогынты ясаган галимнәрнең берсе М.Ф.Бартельс була.

***Дәвамы булачак...***

*Мәгълүмат kpfu.ru сайтыннан алынды*



Инна Басыйрова фотосы

# БӘЙРӘМ КИЛӘ

**Раил САДРЕТДИНОВ**

25 нче ГЫЙНВАР СТУДЕНТЛАРНЫҢ ИҢ КҮҢЕЛЛЕ, КӨТЕП АЛГАН БӘЙРӘМЕ – РОССИЯ СТУДЕНТЛАРЫ КӨНЕ БУЛАЧАК. ИКЕНЧЕ ТӨРЛЕ АНЫ «ТАТЬЯНА КӨНЕ» ДИП ТӘ АТЫЙЛАР.

1755 елның 23 нче гыйнварында (Христиан динендә изге булып саналган Татьянаны искә алу көнендә) Россия императрицасы Елизавета Петровна Мәскәү дәүләт университетына нигез салган Иван Шуваловның прошениесен раслый һәм киләчәктә Россиядә алдынгы фәнни үзәкләрнең берсе булачак Мәскәү дәүләт университетын ачу турында указны имзалый.

Инде XIX гасыр уртасына «Татьяна көне» Мәскәү дәүләт университеты студентлары һәм профессорлары бәйрәменнән Россия интеллигенциясе бәйрәменә әверелә. Россия империясендә студентлар көнен шаулап-гөрләп бәйрәм итәләр. Башта әлеге бәйрәм бары тик Мәскәүдә генә билгеләп үтелә, әмма анда бөтен шәһәр халкы катнаша торган була. Бәйрәм университет бинасында рәсми чыгышлар белән башланып китә.

Октябрь революциясеннән соң Татьяна көне турында сирәк искә алалар, ул бары тик 1995 елда Мәскәү университеты каршында изге Татьяна хөрмәтенә гыйбадәтханә ачылу белән генә яңарыш кичерә. 2005 елда Россия Президенты Владимир Путин указы нигезендә календарьга кабат «Россия студентлары көне» дигән дата өстәлә.

Әлеге яшьлек бәйрәме Казан (Идел буе) федераль университетында да күңелле итеп, зурлап билгеләп үтелә. Бу көнне нинди чаралар үткәреләчәге турында безгә КФУның культура-масса эшләрен оештыру бүлеге җитәкчесе **Регина Халикова** сөйләде:

*– КФУ ректоры **Илшат Гафуров** һәм республика җитәкчеләре катнашында концерт программасы көтелә. Без барлык студентларны, укытучы, профессорларны чакырып калабыз. Бигрәк тә Татьяна исемен йөртүче кызлар игътибар үзәгендә булачак. Бәйрәм, театральләштерелгән тамашадан башланып, УНИКС фойесында интерактив мәйданчыкларда дәвам итәчәк. Ә төп чара – УНИКС сәхнәсендәге концерт. Бәйрәм 15 сәгать 30 минутта башланыр дип көтелә. Форсаттан файдаланып, барлык студентларны әлеге матур бәйрәм белән котлыйм!*

Ә республика күләмендәге төп чара – һәр елны «Россия студентлары көне»ндә игълан ителә торган «Ел студенты» республика премиясен тапшыру тантанасы. Әлеге бәйгедә быел да, университетыбыз данын яклап, күп коллективлар, студентлар чыгыш ясады, үзләренең «Ел студенты» дигән исемгә лаек булуларын дәлилләргә тырыштылар, нәтиҗәләр дә озак көттермәс.

Әлеге күркәм, күңелле бәйрәмнең нәкъ менә 25нче гыйнварда үткәрелүе очраклы түгел. Шушы көннән студентларның кышкы каникуллары башлана. Сессияне койрыкларсыз тапшыргансың икән, нигә әле рәхәтләнеп бәйрәм итмәскә ди?!

# КАМИЛЛЕК ҮРНӘГЕ

ШУШЫ КӨННӘРДӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ ФӘН ҺӘМ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ КОЛЛЕГИЯСЕ КАРАРЫ НИГЕЗЕНДӘ, КФУның ПЕДАГОГИК БЕЛЕМ БИРҮ ИНСТИТУТЫ ДОЦЕНТЫ НАДЕЖДА ЮРИЙ КЫЗЫ КОСТЮНИНА РФ ФӘН ҺӘМ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ ПОЧЕТ ГРАМОТАСЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНДЕ.

**Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ,** педагогика фәннәре докторы, профессор

Әлеге грамота Надежда Юрий кызына фәнни-методик кадрлар һәм белгечләр әзерләү, региональ, федераль, халыкара белем бирү һәм фәнни-техник программалар һәм проектлардагы казанышлары, фәннең приоритетлы юнәлешләре буенча университетара программалар эшләү, студентлар, аспирантлар әзерләү һәм аларның иҗади активлыгын үстерүдәге эшчәнлеге өчен бирелде.

Надежда Юрий кызы белем бирү өлкәсендә 1984 нче елдан бирле эшли. М.Е.Евсеньев исемендәге Мәскәү дәүләт педагогия институтын тәмамлагач, Надежда Юрий кызы укытучы һәм башлангыч мәктәптә, соңрак педагогия көллиятендә уку-укыту буенча директор урынбасары, Чувашия дәүләт университетының Алатыр филиалында тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып, хәзер инде 12 ел буе Казан университетында эшли.

Педагог һөнәрен үзе сайлый, тик бу күпмедер күләмдә гаилә эшен дәвам итү була (Надежда ханымның бабасы — математика, әбисе — башлангыч сыйныфлар укытучысы). Надежда Юрьевна әйтүенчә, нинди генә яшьтә булсаң да, балалар белән эшләү кызыклы һәм мавыктыргыч эш. Педагогика профессия түгел, педагогика — ул фәлсәфә һәм күңел халәте. Надежда Юрьевна сайлаган һөнәрендә үзен тапкан, галим, иҗади педагог буларак ачылган, зур нәтиҗәләргә ирешкән.



Надежда Юрьевна дәресләре һәрчак кызыклы уза, студентларда белем алуга кызыксыну уята. Надежда Юрьевна, үз эшенең остасы, инициативалы, тәҗрибәле педагог буларак, һәрбер студентның сәләтен ачарга, шәхси сыйфатларын үстерергә, беренче карашка тыныч булып күренгән укучының да яшерен талантын күрсәтергә булыша.

Белем бирү һәм фәнни эшчәнлекне бергә алып бару Надежда Юрьевнага дәресләрен югары фәнни-методик дәрәҗәдә, дисциплиналарның бөтен

*Педагогика – ул фәлсәфә һәм күңел халәте*

тәрбияви потенциалын кулланып уздырырга мөмкинлек бирә. Надежда Юрьевна ВАК һәм Scopus базасында теркәлгән журналларда һәрдаим басылып тора, заманча белем бирүне модернизацияләү проектларын эшләүдә актив катнаша.

Галим буларак, Надежда Юрьевна яшүсмерләр һәм яшьләрнең үз-үзләрен тотышындагы тайпылышларны булдырмауга психолого-педагогик ярдәм проблемасын өйрәнә һәм тикшерә. Тәҗрибәле педагог буларак, ул күп тапкырлар «Трансформер», «Педагогический Олимп» Республикакүләм бәйгеләргә, «Казан шәһәренең иң яхшы укытучысы» бәйгесенә казыйлар шурасы рәисе итеп чакырылган.

Хезмәтен профессиональ башкаруы һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен, Н.Ю.Костюнина Почет грамоталары һәм рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән.

Бүгенге көндә Надежда Юрьевна белем һәм тәрбия бирү процессын оештыру һәм камилләштерү, замана укытучысын интеллектуаль, иҗади һәм әдәп-әхлак ягыннан үстерү белән шөгыльләнә.

# ЯҢА ҮЗӘК, ЯҢА МӨМКИНЛЕКЛӘР

ЗӨЯ УТРАУ-ШӘҺӘРЧЕГЕНДӘ КФУның ӨР-ЯҢА МӘГЪЛҮМАТИ БЕЛЕМ БИРҮ ҮЗӘГЕ АЧЫЛА.

«Всемирное культурное наследие» дип исемләнгән әлеге үзәк Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты структурасына керәчәк һәм үзендә белем бирү, тәкъдир итү, күргәзмә залларын берләштерәчәк. Әлеге үзәк Зөя утрау-шәһәрчегенең иң борынгы таш биналарының берсе булган Крылосов йортында булачак. Зур реставрациядән соң, Крылосов йорты «Яңарыш» республика фонды тарафыннан КФУ карамагына тапшырылачак.

Яңа үзәктә абитуриентларга КФУның казанышлары һәм мөмкинлекләре турында мәгълүмат биреләчәк. Моның өчен комплекста махсус презентацион аудитория каралган. Үзәк эшчәнлеге шулай ук Зөя утрау-шәһәрчеге тарихы белән кызыксынган төрле яшьтәге туристларга да файдалы булачак.



● Белми калма!

# UEN – УЕН ЭШ ТҮГЕЛ

**Васил ГАРИФУЛЛИН,** КФУның татар журналистикасы кафедрасы мөдире, профессор

УЗГАН ЕЛ АЗАГЫНДА ХАЛКЫБЫЗНЫҢ МИЛЛИ-РУХИ ТОРМЫШЫНА ЗУР ЙОГЫНТЫ ЯСАРДАЙ ЯҢАЛЫК БУЛДЫ: ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БАЛАЛАР ТЕЛЕКАНАЛЫ АЧЫЛАЧАГЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТЕЛДЕ. ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ **ӘСГАТЬ САФАРОВ** ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ УЗГАН УТЫРЫШТА ТАТАРСТАННЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫНА ШУШЫ ЭШНЕ БАШКАРЫП ЧЫГУ БУРЫЧЫ ЙӨКЛӘНДЕ.

Бала чак искә төшә. Авыл китапханәсендәге китапларны тәмам тузып-таушалып беткәнче, кулдан-кулга йөртеп укый идек. Өстәвенә, өйгә ун-унбишәр төрле газета-журнал алдырабыз. Тормышыбызга телевизор килеп кергәч, яшәү бөтенләй икенчегә әйләнде. Атналык телетапшырулар программасы игълан ителгән газета килеп төшү белән, аны энәсеннән-җебенә кадәр өйрәнеп, киләсе атнада булачак тапшыруларны, мажаралы фильм һәм мультфильмнарны барлап чыгабыз, асларына сыза-сыза билгеләп куябыз. Аннары, кулга шул программаны тотып, түземсезлек белән тапшыру башланганын көтеп утырабыз. Балалар өчен әллә нигә бер була торган татарча тапшырулар — үзе зур бәйрәм кебек иде…

Бүген исә бөтенләй башка вәзгыять. Бала-чаганы китап укыту түгел, телевизор экраны каршында да тота алмыйсың хәзер. Кулларындагы планшет, айфон кебек мобиль җайланмадан үзләренә кирәкле берәр уенны эшкә җигәләр дә көннәр буе виртуаль дөньяда яшиләр. Мондый шартларда балалар өчен яңа телевизион проектны гамәлгә кую — бик нык уйлап эш итүне сорый торган гамәл. Әгәр ул традицион кысаларда эшли торган канал булып кала икән, аңа аудитория туплау бик кыен булачак. Татар телле балалар телеканалы концепциясен төзүче эшче төркемнең министрлыкта узган киңәшмәсендә ТНВ каналы тәкъдим иткән «Күчтәнәч» проекты презентациясе белән танышкач та, башыма әнә шундый уйлар килде. ТНВчылар 6 сәгатькә исәпләнгән гадәти тапшырулар челтәре эшләгәннәр. Шушы алты сәгатьлек тапшырулар марафоны каналда тәүлегенә дүрт тапкыр кабатлап күрсәтеләчәк икән. Монысы җир шарының төрле почмакларында карарга уңай булсын өчен, янәсе. Ләкин моның өчен тагын бер спутник каналы сатып алырга кирәк булачак. Үзе генә дә миллионнарча долларга төшә бу. Кабель телевидениесен файдалана башласаң да, шактый дәүләт акчасын сарыф итәсе. Кыскасы, әлеге проект дәүләт бюджетын берничә йөз миллион сумга «сыгып», ахырда бернинди нәтиҗәгә китерми торган бер «прожект» буларак күз алдына килеп басты. Чөнки аның нигезендә әлеге дә баягы традицион гамәл ята — бала яки аның әти-әнисе телевизор каршында үзләренә яраклы тапшыру башланганын сәгатьләр буена көтеп утырырга тиеш. Юк, җәмәгать, көтеп утырмаячаклар алар. Кабат шул планшетларына әйләнеп кайтып, үзләре яраткан мультикны карарга яки уен уйнарга керешәчәкләр.



Бу уңайдан Казан федераль университетының Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе инновацион проект идеясе белән чыкты. Без тәкъдим итә торган проектның исеме — **UEN TV**. Әлеге проект нигезендә теләсә кайсы мобиль җайланма аша татарча уеннарга, балалар программаларына кереп китү мөмкинлеге каралган. Мавыктыргыч уеннар ярдәмендә балага тиешле тәрбия бирә, аны татарчага өйрәтә торган контент, ягъни тиешле эчтәлекне җиткерергә була.

Бу — традицион телевидение түгел, ә интернет-телевидение. Заманча һәм бик уңайлы вариант. Интернет челтәре аша тапшырыла торган булгач, ул артык кыйбатка да төшми. Төп чыгымнар бары тик контент җитештерүгә генә китәчәк. Аның структурасы һәм эчтәлеге буенча инде концепция эшләнде. Кабул ителсә, без аны университет телевидениесе базасында тормышка ашыра алачакбыз.

Без тәкъдим итә торган проектның тагын бер мөһим ягы бар: анда конвергент шартларда эшли белүче, ягъни мәгълүмат җиткерүнең барлык каналларын да бер үк дәрәҗәдә оста файдалана алучы милли кадрлар әзерләү дә каралган.

Исем мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк. «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе Татарстанның мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә татар телендә балалар каналына исем һәм шигарь уйлап табу бәйгесе игълан иткән иде. «ВКонтакте» челтәре аша тавыш бирү уздырылды. Шунысы аяныч, инде кулланылышта булган примитив һәм балалар өчен кызыксыз «Балачак», «Балалар» атамалары иң күп тавыш

жыйды. Мондый исемне канал атамасы итү бик сәер булыр иде: зурлар өчен телеканалга «Зурлар» дип исем кушкан кебек.

Балалар каналының исеме «UEN TV» булса, ул кыскалыгы белән дә, заманчалыгы белән дә, оригинальлеге белән дә отар иде. Исемендә үк «уен» сүзе булгач, ул баланы кызыксындыра ала. Икенче яктан, «уен» сүзенең инглизчә аббревиатурасына бөтен дөньяга чыга алырдай мәгънә дә сыеша: UEN – Universal Entertainment Network, ягъни универсаль күңел ачу челтәре. Бүгенге глобализация шартларында, инглиз теленең йогынтысы көчле булган заманда, милләттәшләребезнең бөтен дөньяга сибелеп яшәвен дә истә тотсак, моның никадәр мөһим булуы аңлашыла булса кирәк.

Әлбәттә, хикмәт исемдә генә түгел, җисемдә дә! Балалар өчен татарча телеканал бер яктан милли һәм тәрбияви рухлы, икенче яктан бик креатив һәм заманча формалы, мобиль җайланмалар аша керү өчен уңайлы, күп санлы телеканаллар арасында үз йөзе белән аерылып тора алырдай үзенчәлекле дизайнлы, кыскасы, «чәчрәп торган» канал булырга тиеш!



Фотолар Univer TV архивыннан алынды

# «ОЛИМП» БИЕКЛЕГЕНӘ ЮНӘЛЕШ

**Айгөл ГӨСЕЙНОВА,** КФУның телевизион тапшыруларны җитештерү һәм әзерләү кафедрасы укытучысы

ИНДЕ МЕНӘ ИКЕНЧЕ ЕЛ РӘТТӘН, ЯҢА ЕЛ КАНИКУЛЛАРЫННАН СОҢ, СТУДЕНТЛАРНЫҢ СЕССИЯ ТАПШЫРУЫННАН ШАУ-ГӨР КИЛЕП ТОРГАН УНИВЕРСИТЕТ БИНАЛАРЫНЫҢ БЕРСЕНДӘ ТЕЛЕВИЗИОН ТАПШЫРУЛАРНЫ ҖИТЕШТЕРҮ ҺӘМ ӘЗЕРЛӘҮ КАФЕДРАСЫ «ОЛИМП – КЫШКЫ ТЕЛЕВИДЕНИЕ МӘКТӘБЕ»Н АЧЫП ҖИБӘРӘ.

Казан шәһәре мәктәп балалары бер атна дәвамында үзләрен чынчынлап телевидение-радио журналистлары буларак көчләрен сынап карыйлар. Аларга университетның үзендә булган Univer TV каналы базасында барлык шартлар да булдырыла. Иртәдән кичкә кадәр телевизион тапшыруларны җитештерү һәм әзерләү кафедрасы мөгалимнәре, чакырылган практик журналистлар мастер-класс, дәресләр үткәрә, шулай ук, төрле экскурсиялардән тыш, укучы балаларга репортаж төшерү, тавыш яздыру, тапшыру әзерләү белән дә шөгыльләнү мөмкинлекләре тудырыла.

Шушы мәктәпнең җитәкчесе **Альбина Шәкүрова** мәктәп укучыларына университетта бер атна үзләрен телевидение өлкәсендә көч сынап карау бу һөнәрне сайлаганда дөрес күзаллау бирә дип саный.

Быел иң яшь катнашучы 69 нчы мәктәп укучысы **Данил Баров** булды. Ун яшьтә генә булуына карамастан, инде үзенең кесә телефонына тормыш вакыйгаларын видеога төшерү белән мавыга ул. Ә менә «Иннополис» мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы **Надежда Митричева** тормышта төрле яклап белем тупларга, яңалыкларны беренче булып белергә ярата.

**• ЭЛИНА АГРУСЕВА,**
**4 нче интернат-мәктәпнең**
**10 нчы сыйныф укучысы:**

*– Әнием**нең** мине табиб итеп күрергә теләвенә карамастан, киләчәктә минем бик тә журналист һөнәрен аласым килә, чөнки мин үземне бу өлкәдә бераз сынап карадым инде, мәктәп газетасының хәбәрчесе булып торам, тагын әле музыка, волейбол белән дә шөгыльләнәм.*

**• ПОЛИНА ШАЛАБАНОВА,**
**102 нче гимназиянең 10 нчы сыйныф укучысы, шулай ук «ТИН-клуб» корреспонденты:**

*– Минем журналистика белән кызыксынуым «Яшь журналистлар мәктәбе»ннән башланды. Аннары мин «Алтын каләм» фестивалендә катнаштым, шунда мин телевидение белән кызыксынып киттем.*

---

***PS.*** Яшьтәшләренә үрнәк булырдай талантлы балалар, тормышларында дөрес юнәлеш алып, хәтта «Олимп» биеклекләренә дә күтәрелә алырлар дип ышанып калыйк.

**• ЭЛИНА МАЛИКОВА,**
**23 нче урта мәктәпнең**
**11 нче сыйныф укучысы:**

*– Мин бик тә хисчән кеше: кечкенәдән шигырьләр язам, укырга һәм язарга яратам, үземнең шәхси блогымны алып барам. «Олимп – кышкы телевидение мәктәбе» турында мин укытучымнан белдем. Үземә күп мәгълүмат алдым, «Телевидение» юнәлеше буенча укырга керергә җыенам.*

Россиянең Матбугат көнендә КФУда заманча җиһазланган, Татарстанда бердәнбер **Шоу-рум** универсаль телестудиясе үз эшен башлап җибәрде.



# ЯЛКАУЛАНМАСКА ГЫНА КИРӘК!

**Ләйлә САБИРОВА**

**БҮГЕН «ШӘХЕС» РУБРИКАСЫНЫҢ КУНАГЫ – ЯШЬ, ЧИБӘР ҖЫРЧЫ, КҮП КОНКУРСЛАР ҖИҢҮЧЕСЕ, 250гә ЯКЫН ДИПЛОМ ИЯСЕ, КФУ СТУДЕНТЫ ГӨЛНАЗ ГАРИФҖАНОВА. ҖЫР-МОҢГА ГАШЫЙК КЫЗ БАЛАЧАКТАН УК СӘХНӘДӘ. БАРЫСЫ ДА «СОЗВЕЗДИЕ-ЙОЛДЫЗЛЫК» БӘЙГЕСЕННӘН БАШЛАНДЫ, ДИП СӨЙЛӘП КИТТЕ УЛ ҮЗЕ ТУРЫНДА.**

Гөлназ Гарифҗанова катнашкан һәм урыннар алган бәйгеләр бик күп. «Дулкыннар», «Сандугач керде күңелгә», «Ватан», «Созвездие-Йолдызлык», «Сөембикә варислары» (Кырым, Ялта), «Звездная юность планеты» (Сочи), «Татар моңы», «Галәм гүзәле-2008» (Мисыр), «Талант» (Яр Чаллы), «Татар кызы-2015», «Болгар радиосы» милли музыка премиясе һәм башкалар.

**— Җыр өлкәсендә беренче укытучың кем иде?**

— Гыйниятуллина Заря Галимҗан кызы. Мине дөрес һәм матур итеп җырларга ул өйрәтте. Аңа бик рәхмәтлемен! Заря ханым — чын укытучы, ярдәмче, авыр чакта терәк була белүче. Миңа биргән һәрбер дәресе әле дә күз алдымда. Җырларга җиңел диләр, бер дә җиңел түгел, дусларым. Ходайдан бирелгән сәләт белән генә ерак китеп булмый икән, үзеңне камилләштерү өчен ныклап эшләү мөһим. Көненә ике сәгать булса да җырларга кирәк, җырламасаң — тавыш утыра.

**— Кайсы бәйгене еш искә төшерәсең?**

— 11 нче сыйныфта укыганда, Казанга килеп, кытай теленә багышланган фестивальдә катнашуымны. Конкурс башланырга өч көн калган иде. Тиз генә туганым Марсель абыйга шалтыратып, миңа шушы эшне башкарып чыгарга ярдәм итүен сорадым, чөнки ул — Кытай һәм Россия дипломаты. Аннан бер-ике дәрес алдым, ул миңа сүзләрне дөрес итеп әйтергә өйрәтте. Җырны да бергәләп сайладык. Марсель абый миңа «Тычкан дөге ярата» исемле кытай халык җырын тәкъдим итте. Миңа бу җырның көе дә, сүзләре дә бик ошады. Шулай итеп, кытай теленә, аның мәдәниятенә гашыйк булдым. Конкурс уздырыласы көн тиз килеп җитте. Сәхнәсе зур, иркен. Иплап кенә вак-вак атлап кытай костюмында чыктым да, матур итеп «кытайларча» баш идем. Тамаша залы тын калды. Иң бәхетле мизгелләрем!.. «Беренче урын Гөлназ Гарифҗановага тапшырыла», дигәч, мин башта ышанмый тордым. Кая инде?! Кукмара районыннан килгән 11 нче сыйныф укучысы, өч көн эчендә



әзерләнеп, беренче урын алсын икән?! Катнашучылар арасында кытай телен үзләштерүче студентлар да бар иде бит. Башка сыймаслык хәл булды бу минем өчен. Матур бүләк белән кайттым, күп дуслар таптым. Хәзер минем Кытайдан килгән дусларым да

*Яшь чакта яшьнәп калырга кирәк. Бер тапкыр гына яшибез бит!*

бар, аларны концертларыма чакырам.

**— Илһам Шакиров та бит «эшләмим, җырлап йөрим» дип шаяра иде, ә чынлыкта җырчы булу авырмы?**

— Җырчы булуымның да авыр чаклары була. Һәрвакыт үз-үзеңне карап, шарф белән төренеп, җылы баш киеме белән йөрергә туры килә. Салкын ризык, көнбагыш-чикләвек ашамаска, газлы су эчмәскә... Менә шулай, үзеңне чикләп яшәү рәхәт түгел. Гел иренмичә җырларга, тавышны көйли торган күнегүләр эшләргә, репертуарны җитди сайларга кирәк. Мин җырчы гына булып калырга теләмим. КФУда да шулай ук иҗади белгечлекне — журналистиканы үзләштерәм. Хәзер дүртенче курста укыйм.

**— Сез гаиләгез белән «Нечкәбил» XII Республикакүләм гаилә һәм аналар бәйгесендә дә катнашкансыз икән.**

— Әйе, 2016 елда «Нечкәбил»дә дә көч сынаштык. Бик күркәм бәйге ул. Иң беренче чиратта, мин әти-әниемә рәхмәтлемен. Алар миңа һәрвакыт этәргеч көч биреп тордылар, авыр чакта ярдәм кулы суздылар. Җыр белән шөгыльләнүемә каршы килмәгәннәре өчен аларга аеруча рәхмәтлемен. Баласына каршы килә торган әти-әниләр дә бар бит. Андый баланың теләкләре чынга ашмый инде, хыял гына булып кала. Барысына да өлгерергә тырышам. Ялкауланмаска гына кирәк!

2015 ЕЛДА «ДӨНЬЯ БУЙЛАП РУС ТЕЛЕ ИЛЧЕЛӘРЕ» ПРОГРАММАСЫ ТӨЗЕЛӘ ҺӘМ КҮПЛӘРНЕҢ ТОРМЫШЫНА ЗУР ШАУКЫМЛЫ ПРОЕКТ БУЛЫП КИЛЕП КЕРӘ. ӘЛЕГЕ ПРОЕКТ БЫЕЛ ДА ТӨРЛЕ ИЛЛӘРНЕ ҺӘМ ЙӨЗЛӘГӘН КЕШЕНЕ БЕРЛӘШТЕРДЕ.

# РУС ТЕЛЕ ИЛЧЕСЕ КАЙДА ӘЗЕРЛӘНӘ?

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

Бу хакта без КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Рус теле һәм кулланма лингвистика кафедрасы аспиранты **Гөлназ Мәрданова** белән сөйләштек.

**— Гөлназ, бу проект турында җентекләбрәк сөйлә әле.**

— «Послы русского языка в мире» — ул халыкара волонтерлык проекты. Аның төп максаты — Россиядә һәм чит илләрдә рус теле, әдәбияты һәм мәдәниятен популярлаштыру, университетлар арасында партнерлык мөнәсәбәтләре булдыру, әйләнә-тирәдәгеләрне мәдәни толерантлык белән таныштыру. Әлеге программа белем бирү экспедицияләре кысаларында студентларга һәм аспирантларга Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә стажировка узу мөмкинлеге бирә.

**— Волонтерлар ничек сайлап алына?**

—Волонтерларга карата аерым таләпләр бар. Беренчедән, волонтер студент, аспирант яки яшь белгеч булырга тиеш. Икенчедән, кандидат 18 яшьтән кече, 30дан олы булмаска тиеш. Өченчедән, рус телен, әдәбиятын камил белергә, мәдәният һәм тарих буенча да мәгълүматлы булырга тиеш. Моннан тыш, башка мәдәният һәм милләтләр белән танышу, аларны өйрәнү теләге һәм, әлбәттә инде, волонтерлык, педагогик эшчәнлек буенча тәҗрибәсе булу да таләп ителә.

**— Син бу программага ничек килеп кердең?**

— Дөресен генә әйткәндә, программаның читтән торып катнашу этабын узуым үзем өчен дә көтелмәгән вакыйга булды. Әлеге программада катнашу өчен бөтен дөньядан барлыгы 3000гә якын гариза җибәрелгән була. Ә төп этапка нибары 100 кеше генә сайлап алынды.

**— Нинди сынаулар уздыгыз?**

— 7-11 нче сентябрь көннәрендә Оренбург шәһәрендә «Евразия» форумы булды. А.С.Пушкин исемендәге Рус теле дәүләт институты мөгаллимнәренең махсус лекцияләрен тыңладык, осталанәләр эшендә катнаштык, рус телен популярлаштыру буенча төрле акцияләр әзерләдек һәм аларны якладык, дәрес фрагментлары күрсәттек. Төп этапка узган 100 кеше арасыннан кырык җидебезгә программада катнашучы статусы бирелде. Октябрь-ноябрь айларында без читтән торып белем алдык, ә декабрьдә беренче экспедицияләргә киттек.

**— Синең экспедицияң кайда узды?**

— Миңа экспедициене Таҗикстан Республикасында узу бәхете насыйп булды. Без, программаның 15 катнашучысы, Дүшәнбе шәһәре мәктәпләре укучыларына рус теле дәресләре бирдек, рус мәдәнияте белән таныштырдык.

**— Экспедициядән соң катнашучыларны нәрсә көтә?**

— Программаны һәм экспедициене уңышлы узган катнашучыларга «Рус теле илчесе» статусы бирелде. Экспедиция тәмамлангач, Мәскәүдә Йомгаклау форумында катнаштык, эшчәнлегебезгә нәтиҗәләр ясадык һәм Программаның киләчәк планын төзедек.




Фотолар герой архивыннан

*2016 елда Бахрейн, Перу, Эквадор, Кытай, Башкортстан, Чечня һәм Абхазиягә экспедицияләр оештырылган*



# Яңа фикерле «Яңа дулкын»

Айгөл АБДРАХМАНОВА

**2016 ЕЛ АЗАГЫНДА Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНЫҢ КЕЧЕ СӘХНӘСЕНДӘ «ГОЛОС» ТАПШЫРУЫ БУЛДЫ. ӘЙЕ, ЧЫП-ЧЫН «ГОЛОС». ТИК АЛЫП БАРУЧЫ ДМИТРИЙ НАГИЕВ УРЫНЫНДА РҮЗӘЛ ӘХМӘДИЕВ, ӨЧ КАЗЫЙ УРЫНЫНА – АЛТЫ, Ә КАТНАШУЧЫЛАР ИСӘ – ҮЗЕБЕЗНЕҢ КФУ СТУДЕНТЛАРЫ.**

Ноябрь аенда шигырь белән җенләнгән һәм иҗат нәтиҗәләре белән бүлешергә теләгән студентлар өчен «Калеб. Яңа дулкын» дип исемләнгән махсус проект тәкъдим ителде. 19 нчы гыйнвар көнне КФУ студентлары катнашында «Калеб. Яңа дулкын» проектының дәвамын — икенче кисәген тамаша кылдык.

Театральләштерелгән иҗат кичәсе бик күпләрне таң калдырды, көндәлек проблемаларга яңача карарга мөмкинлек бирде.

**• АЛСУ СӘЛАХОВА:**

«Еш кына шигырь язучылардан «Сезне нәрсә илһамландыра?» дип сорыйлар. Билгеле, илһам чыганагы күп булырга мөмкин. Соңгы айларда мин шундый яңа «чишмә» белән таныштым. Ул да булса, «Калеб. Яңа буын иҗатчылар җыены». 17 нче ноябрь көнне булып узган сайлау турыннан әлеге кичә нәрсәсе белән аерылды соң? Тулысынча башка атмосфера, әмма бер әйбер үзгәрешсез калды, ул да булса — шигырьләр укылу. Әлеге чара композитор белән шагыйрь дуэтының театральләштерелүе формасында узды. Сессия депрессиясе белән җәфаланган студентларга дәвалану ысулын тәкъдим иттек. Кичәнең төп темасы — депрессия халәте һәм аннан чыгу. Хәер, барлык яшь шагыйрьләр дә моннан котыла аламы икән?»



**• ӘМИНӘ МИНДИЯРОВА (режиссер):**

«Мин бу эшкә үземне тагын бер кат сынап карар өчен алындым. Укырга кергәнче, мәдрәсәдә дә, мәктәптә дә шундый чаралар үткәрә идек. 4 курста һөнәри яктан үземнең ничек үзгәргәнемне беләсем килде. Беренче «Яңа дулкын»да шигырьләрне мин бик кабул итә алмадым. Ә шагыйрьләрнең үзләре белән аралаша башлагач, шигырьләр күңелемә үтеп керде. Көндәлек тормыш турындагы уйларын алар шигъри калыпка сала. Икенче «Яңа дулкын»ны ничек тәкъдим итәргә икән дип уйландым, бу авыр мәсьәлә иде. Коръәндә минем яраткан аятем бар: һәр авырлыктан соң бер җиңеллек килә. Проблемалар онытыла, җиңеллек кала. Безнең депрессияле заманда зарланырга ярамаган совет чорын еш искә алабыз. Ә хәзер социаль челтәрләрдә кешеләр эшләреннән, укудан зарлана һәм ул аңга тәэсир итә, кешеләрне борчуга сала. Депрессиядән чыгарга бары дини тормыш кына ярдәм итә. Кичәбездә шул хакыйкатьне ачып бирергә тырыштык».

*«Калеб. Яңа дулкын» проекты һәм әзерлек процессыннан кайбер мизгелләр*

**• ЛӘЙЛӘ ХӘБИБУЛЛИНА:**

«Яңа дулкын» бик дулкынланып көтеп алган чара булды. Ул зур сәхнәгә чыгарга мөмкинлек бирде. Алдагы этапта шигырьне укып, кызыклы һәм файдалы фикерләр тыңлап «котылган» булсак, бу юлы шигырьне сәхнәдә яшәп күрсәтергә, тамашачының күңелен иҗат дулкыны белән яулап алырга кирәк иде.

«Калеб» проекты безгә үзебезне үстерер өчен зур мөмкинлек бирде. Чөнки безнең белән **Илдус Әхмәтҗанов**, **Зөлфия Вәлиева** кебек танылган һәм хөрмәтле кешеләр эшләде, барысына да өйрәтте. Режиссерыбыз **Әминә Миндияровага** идеяләре, сабырлыгы, тырышлыгы өчен зур рәхмәт әйтми булмый. «Яңа дулкын» проекты финалы — күпләрнең гыйнвар аенда иң көтеп алган чараларының берседер. Шуңа күрә, шәхсән мин үзем бик зур җаваплылык тойдым».

12+
DARELFONUN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Р.Садретдинов, А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – ФГАОУ ВО Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 334 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2016 елның 08 сентябрендә ПИ № ТУ 16-01506 нчы танылык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 19.01.2017. «Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.